**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **12.11.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге составына керүче, Ирекле авылында 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлегендә, Ирекле авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Чалпы авыл җирлеге Ирекле торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:
- Ирекле авылында Гагарин, Наратлы урамнары буенча вак таш җәелгән юлларның чокырларын ямау (ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Ирекле авылында урамнарны яктырту өчен яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампалар урнаштыру, эшләр өчен түләү;
- Ирекле авылы зиратлары өчен җиһазлар һәм инвентарь ( генератор) сатып алу;
- Ирекле авылында янгын сүндергечләр, янгын сундерү ранецлары, янгынга каршы инвентарь сатып алу;
- Ирекле юлларын кардан чистарту;
- Ирекле авылы территориясен җәйге чорда чабу;
- Ирекле авылында коры агачлар, куакларны кисү;
- Ирекле авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Ирекле авылында һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәлләрне ремонтлау (койма урнаштыру, буяу, агарту, килешү буенча эш өчен түләү) ;
- Ирекле авылында «Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: ТР, Азнакай муниципаль районы, Ирекле авылы, Ирекле авылы мәдәният йорты.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чалпы авыл җирлеге Башлыгы: А.М. Мөхәмәтшин